**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

06.09.2018 № 294

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2014 елның 13 декабрендәге 707 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 30 июлендәге 439 номерлы, 2016 елның 5 апрелендәге 221 номерлы, 2017 елның 9 гыйнварындагы 2 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге 342 номерлы һәм 2017 елның 16 декабрендәге 731 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Эш төркеме составыннан А.А. Здуновны, Э.Р. Лабашованы чыгарырга;

Эш төркеме составына кертергә:

Закиров Әнвәр Фәрит улын – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасының баш суд приставы урынбасарын (килешү буенча);

Пелевин Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ